КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 апрель г.Казань № 254

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте, ирекледек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август 756 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 июнь, 558 нче; 2023 ел, 6 февраль, 107 нче; 2023 ел, 13 май, 589 нчы; 2023 ел, 22 июнь, 736 нчы, 2023 ел, 4 декабрь, 1551 нче, 2024 ел, 10 гыйнвар, 1 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яшьләр сәясәте, ирекледек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидияләр түбәндәге кысаларда бирелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 05 март, 158 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасының

«Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» төбәк проекты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сенябрь, 821 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 25 август, 730 нчы карары белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы.»;

9 пунктның җиденче абзацында «экипировка,» сүзеннән соң «обмундирование,» сүзен өстәргә;

13 пунктта:

сигезенче абзацка «мөһере» сүзеннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә;

уникенче абзацка «мөһере» сүзеннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны тормышка ашыруга коммерциячел булмаган оешмаларга, физик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 гыйнвар, 29 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 19 июнь, 730 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны тормышка ашыруга коммерциячел булмаган оешмаларга, физик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның икенче – бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 05 март, 158нче карары белән расланган

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы»;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» төбәк проекты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сенябрь, 821 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы.»;

3.4 пунктның бишенче абзацына «мөһере белән» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында «М.У.» аббревиатурасыннан соң «(булганда)» сүзен өстәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие - Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивале чараларын үткәрүгә бәйле коммерциячел булмаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 06 июнь, 528 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 16 март, 256 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Созвездие - Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивале чараларын үткәрүгә бәйле коммерциячел булмаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 05 март, 158 нче карары белән расланган «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче

карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасы  Икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен  үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 05 март, 158 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы  Икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы  Икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның унбишенче абзацына «мөһере белән» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Талантлы һәм социаль мохтаҗ студент яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү конкурсын оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 29 сентябрь, 1051 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 06 сентябрь,  1084 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Талантлы һәм социаль мохтаҗ студент яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү конкурсын оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында»  2019 ел, 05 март, 158 нче карары белән расланган «2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен  үстерү» дәүләт программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен  үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын  раслау турында»  2019 ел, 5 март, 158 нче карары белән расланган  «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен  үстерү» дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта:

унберенче абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

уналтынчы абзацка «мөһере» сүзеннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә.

5. Әлеге карар, 2024 елның 1 июненнән үз көченә кертә торган әлеге карарның 1 пунктындагы уникенче - ундүртенче абзацларыннан, 2 пунктындагы җиденче һәм сигезенче абзацларыннан, 3 пунктындагы  өченче абзацыннан,4 пунктындагы өченче - бишенче абзацларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин